ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 10[1] статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10[1] статьясындагы 8 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), «дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы яисә җирле үзидарә органы, Россия Федерациясе яисә Татарстан Республикасы тарафыннан төзелгән һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган юридик зат» сүзләрен «торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында күрсәтелгән затлар» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 73-ТРЗ